**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.01.2019г. № 15

**"2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүне үстерү"максатчан программасын раслау турында**

Әтнә муниципаль районында мәктәпкәчә белемнең һәркем өчен мөмкин булуына дәүләт гарантияләрен тәэмин итү максатларында карар бирәм:

1. "2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүне үстерү" максатчан программасын расларга

2. Балалар бакчалары мөдирләре тарафыннан район максатчан программасын тормышка ашыру планын эшләргә.

3. Әлеге программаның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге” МКО башлыгына йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы
башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Ф.Каюмов.

"2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирүне үстерү" максатчан программасын раслау турында 21.01.19 №15 номерлы карарга

килештерү, адреслау,танышу кәгазе.

Башкаручы: “Мәгариф бүлеге” МКО башлыгы Л.Т.Гарипов.

Килешенде

| Вазифа | Исем, Фамилия | Имза, дата |
|---|---|---|
| “Мәдәният бүлеге” МКО әйдәп баручы белгече | Касимова А.Р. | |
| Әтнә районы башкарма комитеты әйдәп баручы белгече | Галлямова Р.М. | |

КАРАЛДЫ

Татарстан Республикасы

Әтнә муниципаль районы

башкарма комитеты

Карары

№ 15 21.01.2019

# 2019-2023 нче елларга «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүне үстерү” район максатчан программасы

**Олы Әтнә, 2019**

## 2019-2023 нче елларга «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүне үстерү” район максатчан программасы

## ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2019-2023 нче елларга «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүне үстерү” район максатчан программасы |
| Программаның муниципаль заказчы-координаторы | Әтнә районы башкарма комитеты |
| Программаның муниципаль заказчысы | ТР Әтнә районы башкарма комитеты “Мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе |
| Программаны төзүче | ТР Әтнә районы башкарма комитеты “Мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе |
| Программаны тормышка ашыручылар | -ТР Әтнә районы башкарма комитеты “Мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе;<br>Әтнә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре |
| Программаның максаты | Муниципаль мәктәпкәчә оешмалар челтәрен үстерү хисабына мәктәпкәчә белемнең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | 1.Ведомство карамагындагы учреждениеләр эшчәнлеген (мәктәпкәчә белем бирүне оештыру буенча хезмәтләр күрсәтүне) тәэмин итү, шул исәптән муниципаль бюджет учреждениеләренә субсидияләр бирү.<br>2. Мәктәпкәчә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларында өстәмә урыннар булдыру |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2019-2023 нче еллар |
| Программаны финанслау | Программаны финанслау башкарыла:<br>-җирле бюджет хисабына,<br>-федераль бюджет хисабына. |
| Программаның көтелгән нәтиҗәсе | 1. 2023 елга мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар кытлыгын бетерү<br>2. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүче Федераль дәүләт стандартларына туры килә торган программалар буенча белем алучы укучыларның гомуми сандагы тәрбияләнүчеләргә чагыштырма авырлыгын 2023 нче елга 100 % итү. |

## 1. Әтнә районы мәктәпкәчә белем бирү системасының торышы

Әтнә муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү системасы мәктәпкәчә белемгә дәүләт гарантияләрен тәэмин итү максатында эшли, бу исә халыкның мәктәпкәчә белем алуга булган ихтыяҗын канәгатьләндерү бурычларын тормышка ашыруны күздә тота. Әтнә районының мәктәпкәчә белем бирү системасын 13 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе һәм 1 башлангыч мәктәп-балалар бакчасы тәшкил итә. 2019 елның 1 гыйнварына мәктәпкәчә белем бирүне колачлау 57% тәшкил итә. Алдагы программаны гамәлгә ашыру барышында әлеге күрсәткечне 11% ка арттыруга ирешелде. 2014 елда Түбән Көек, Коморгуҗа, 2018 елда Ташчишмә авылларында балалар бакчалары ачылганнан соң, Әтнә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре булмаган авыл җирлекләре калмады.

Шул ук вакытта районда мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләренә ихтыяҗ бар. Балалар бакчаларына чират "Электрон балалар бакчасы" системасы ярдәмендә җайга салына. 2019 елның 1 гыйнварына чиратта торучы балалар саны - 153, шуларның 112 се - 1 яшьтән 6,5 яшькә кадәрге балалар. Чиратта торучыларның күпчелеге район үзәгендә урнашкан "Олы Әтнә балалар бакчасына туры килә.

Барлык белем бирү учреждениеләре дә срогы чикләнмәгән лицензиягә ия. Мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләргә анализ шуны күрсәтә: укыту-тәрбия процессы нигездә "Туган йорттан мәктәпкә кадәр" дигән төп белем бирү программасына (Н.Е.Веракса, Т. С. Комарова, М. А. Васильева редакциясе) таянып алып барыла. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен учреждениеләрдә өстәмә белем бирү хезмәтләре күрсәтелми. Инновацион белем бирү программаларын үзләштерү һәм гамәлгә кертү процессы акрын бара. Мәктәпкәчә белем бирүнең яңа заманча сыйфатына ирешү максатында яңа буын программаларын һәм технологияләрен практикага кертергә кирәк. Мәктәпкәчә һәм башлангыч белем баскычларының дәвамчанлыгы тәэмин ителә. Районның мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балалар бакчаларына йөрмәүче 5 - 6,5 яшьлекләр өчен мәктәп алды әзерлеге оештырыла һәм ул балалар санының 100% ын тәшкил итә .

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә эшләүче педагогик хезмәткәрләренең кадрлар составын анализлау шуны күрсәтә: педагогик хезмәткәрләрнең 82% ы - югары белемле (2013 елда – 52%), 18% ы – урта һөнәри белемле. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең 6 сында музыка җитәкчесе, 1 сендә логопед һәм физкультура инструкторы эшли.

Бүгенге көндә мәктәпкәчә белем бирүнең сыйфатын тәэмин итүдә әлеге учреждениеләрдә эшләүче педагогларның һөнәри дәрәҗәсе мөһим. Мәктәпкәчә учреждение җитәкчеләренең һәм педагогик персоналларның квалификациясен күтәрүгә аерым игътибар бирергә кирәк.

Соңгы 5 елда МБМББУ "Күәм балалар бакчасы", МБМББУ "Кышлау башлангыч мәктәп-балалар бакчасы", МБМББУ "Олы Мәңгәр балалар бакчасы" биналарына капиталь ремонт үткәрелде, МБМББУ "Күшәр балалар бакчасы", МБМББУ "Күңгәр балалар бакчасы"нда яңа биналар төзелде. Шул ук вакытта МБМББУ "Күлле-Киме балалар бакчасы", МБМББУ "Олы Әтнә балалар бакчасы", МБМББУ "Дусым балалар бакчасы",

МБМББУ “Түбән Бәрәскә балалар бакчасы” биналарына ремонт ясау сорала. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең кайберләрендә матди-техник яктан тәэмин ителеш федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә тулысынча туры килеп бетми: МБМББУ “Түбән Бәрәскә балалар бакчасы”, МБМББУ “Ташчишмә балалар бакчасы” һәм МБМББУ “Күңгәр балалар бакчасы” Интернет челтәренә тоташтырылмаган.

## II. Программаның максат һәм бурычлары

Программаның максаты – Әтнә муниципаль районында сыйфатлы мәктәпкәчә белем бирүне тәэмин итү.

Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

1. Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген (мәктәпкәчә белем бирүне оештыру буенча хезмәтләр күрсәтүне) тәэмин итү, шул исәптән муниципаль бюджет учреждениеләренә субсидияләр бирү.
2. Мәктәпкәчә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларында өстәмә урыннар булдыру.

Программаны тормышка ашыруның төп күрсәткечләре түбәндәгеләр:

- мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында урыннар кытлыгын бетерү;
- мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында федераль дәүләт белем бирү стандартларына туры килә торган программалар буенча тәрбияләнүчеләр саны 2023 елда 100% тәшкил итүенә ирешү.

Программаны гамәлгә ашыру вакыты: 2019 - 2023 еллар дәүләт программасын гамәлгә ашыру чоры дәвамында.

## III. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫНЫҢ КЫСКАЧА ТАСВИРЛАМАСЫ

“Ведомство буйсынуындагы учреждениеләр эшчәнлеген (мәктәпкәчә белем бирүне оештыру буенча хезмәтләр күрсәтүне) тәэмин итү, шул исәптән муниципаль бюджет учреждениеләренә субсидияләр бирү” бурычын үтәү өчен түбәндәге төп чараларны тормышка ашырырга кирәк:

1. Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында гражданнарның түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итү.

Әлеге чараны гамәлгә ашыру мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының гражданнарга түләүсез сыйфатлы мәктәпкәчә белем бирү буенча эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

2. Әтнә муниципаль районының мәгариф оешмаларында мәктәпкәчә белем бирү ФДББС ын гамәлгә ашыру.

Әлеге чараны гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә юнәлдерелгән: муниципаль белем оешмаларының мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт стандартын гамәлгә ашыру буенча, төп белем бирү программаларын эшләү, мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү буенча эшен оештыру.

"Мәктәпкәчә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларында өстәмә урыннар булдыру" бурычын үтәү өчен, түбәндәге төп чараларны гамәлгә ашырырга кирәк:

1. Районда мәктәпкәчә белем бирү системасын модернизацияләү.

## IV. ПРОГРАММАНЫҢ АХЫРГЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ ФАРАЗЫ

| № | Күрсәткеч атамасы, үлчәү берәмлеге | Башкаручы | 2019 нчы ел | 2020 нче ел | 2021 нче ел | 2022 нче ел | 2023 нче ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына чиратны бетерү, % | “Мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе | 3 | 2 | 1,5 | 1 | 1 |
| 2 | Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары объектларының тузу дәрәҗәсе, % | “Мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе | 30 | 30 | 30 | 35 | 35 |
| 3 | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүче Федераль дәүләт стандартларына туры килә торган программалар буенча белем алучы укучыларның гомуми сандагы тәрбияләнүчеләргә чагыштырма авырлыгы, % | “Мәгариф бүлеге” муниципаль казна учреждениесе | 90 | 100 | 100 | 100 | 100 |

## V. ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ

**(республика һәм муниципаль бюджетның төп чаралары кысаларында, шулай ук программаны гамәлгә ашыру еллары буенча)**

Программаны тормышка ашыру өчен бюджет ассигнованиеләре күләме – 309848,5 мең сум, шул исәптән еллап:

2019 нчы ел – 60689,3 мең сум;

2020 нче ел (фараз) – 61323,7 мең сум;

2021 нче ел (фараз) – 62012,6 мең сум;

2022 нче ел (фараз) – 62632,6 мең сум;

2023 нче ел (фараз) – 63190,3 мең сум.

| **Финанслау чыганаклары** | **2019** | **2020** | **2021** | **2022** | **2023** |
|---|---|---|---|---|---|
| Ата-аналар взносы | 15582,2 | 16080,3 | 16624,5 | 16790,8 | 16933,7 |
| Бюджеттан тыш чыгымнар | 135 | 13,5 | 13,5 | 13,5 | 13,5 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Җирле бюджет | 45093,5 | 45229,9 | 45374,6 | 45828,3 | 46243,1 |

## VI. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ

| | Эшчәнлекнең төп юнәлешләрен тормышка ашыру чаралары һәм механизмнары | Финанслау чыганаклары (мең сум) | 2019 нчы ел | 2020 нче ел | 2021 нче ел | 2022 нче ел | 2023 нче ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| **1.Мәктәпкәчә белем бирү системасын үстерү** | | | | | | | |
| 1 | Педагогларның һәм хезмәт күрсәтүче персоналның хезмәт хакы | ҖБ | 35483,3 | 35471,3 | 35504,6 | 35859,6 | 36218,2 |
| 2 | Белем бирү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту | ҖБ | 2315,2 | 2315,2 | 2315,2 | 2338,3 | 2338,3 |
| | | Ата-аналар взносы | 2212,6 | 2212,6 | 2212,6 | 2234,8 | 2234,8 |
| 3 | Белем бирү учреждениеләренең мөлкәтен саклау һәм төзекләндерү буенча шартлар тудыру | ҖБ | 4739,3 | 4739,3 | 4905,4 | 4905,4 | 5004,0 |
| 4 | Белем бирү учреждениеләрендә балаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү:<br>- биналарны һәм территорияләрне видеокүзәтү системалары белән тәэмин итү;<br>Куркынычсызлык системаларына хезмәт күрсәтү:<br>-АПС;<br>-“тревога кнопкалары” | ҖБ | 470,4 | 470,4 | 470,4 | 475,1 | 475,1 |
| 5 | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре челтәрен һәм мәктәпкәчә белем бирү процессын оештыруның яңа формаларын үстерү | ҖБ | 423,9 | 423,9 | 423,9 | 428,1 | 428,1 |
| 6 | Нотариаль хезмәтләр | ҖБ | 27,4 | 27,4 | 27,4 | 27,7 | 27,7 |
| 7 | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең идарә итү системасын мәгълүмати тәэмин итү | ҖБ | 46,0 | 46,0 | 46,0 | 46,5 | 46,5 |
| 8 | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре педагогларының квалификациясен күтәрү | ҖБ | 63,9 | 63,9 | 63,9 | 64,6 | 64,6 |
| 9 | Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү | ҖБ | 612,0 | 635,2 | 660,6 | 667,2 | 673,9 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | учреждениеләрендә туклану сыйфатын яхшырту | Ата-аналар взносы | 13107,6 | 13605,7 | 14149,9 | 14291,4 | 14434,3 |
| 10 | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең салым базасын тәэмин итү | ҖБ | 921,2 | 921,2 | 921,2 | 930,4 | 930,4 |
| 11 | Заманча дидактик уеннар, методик материаллар сатып алу | ҖБ | 36,0 | 36,0 | 36,0 | 36,4 | 36,4 |
| | | Ата-аналар взносы | 262,0 | 262,0 | 262,0 | 264,6 | 264,6 |
| | | Бюджеттан тыш | 13,5 | 13,5 | 13,5 | 13,5 | 13,5 |
| | **Барлыгы** | | **60689,3** | **61323,7** | **62012,6** | **62632,6** | **63190,3** |
| | **Шул исәптән** | **Ата-аналар взносы** | **15582,2** | **16080,3** | **16624,5** | **16790,8** | **16933,7** |
| | | **Бюджеттан тыш** | **13,5** | **13,5** | **13,5** | **13,5** | **13,5** |
| | | **ҖБ** | **45093,5** | **45229,9** | **45374,6** | **45828,3** | **46243,1** |